ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 19 от «23» 01 2019 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
2015 елның 1 нче июлендә кабул ителгән
687 нче санлы карарына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында

2006 елның 13 мартындагы “Реклама турындагы" 38-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешү буенча түләүне исәпләүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1.Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын (реклама конструкцияләрен) урнаштыру һәм эксплуатацияләү кагыйдәләрен раслау турында”(2018 елның 25 декабрендәге 614 номерлы карарындагы үзгәрешләре белән) 2015 елның 1 нче июлендә кабул ителгән 687 нче санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:
1 нче санлы кушымтаның 5.1.пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) реклама конструкциясе хуҗасы тарафыннан рөхсәтне алга таба куллануда баш тарту турында язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталларын кулланып хәбәрнамә җибәргәннән соң бер ай эчендә;

1 нче санлы кушымтаның 4.12. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4.12. Рөхсәт бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында карар Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан язма рәвештә яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталларын кулланып язма рәвештә яки электрон документ рәвешендә мөрәҗәгать итүчегә аның тарафыннан кирәкле документлар кабул ителгән көннән алып ике ай эчендә җибәрелергә тиеш.

Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелгән вакыт эчендә рөхсәт бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында карар алмаган

мөрәҗәгать итүче өч ай эчендә җирле үзидарәнең гамәл кылмавын законсыз дип тану турында гариза белән судка яки арбитраж судына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2.Әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов